РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ТИМЕРШИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422057, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19 а
тел. (84362) 2-23-23

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТИМЕРШЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422057, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Тимершык авылы, Пионер урамы, 19 а йорт
тел. (84362) 2-23-23

e-mail: Timer.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
08.04.2021

КАРАР
№11

Саба муниципаль районы Тимершык
авыл җирлеге Советының 2019 елның
03 июлендәге 18 номерлы карары белән
расланган Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Тимершык авыл
җирлеге территориясендә гражданнар
арасында сораштыру үткәрү һәм
билгеләү тәртибе турындагы
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү
турында

2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 03 июлендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 17.1. пунктының 2 абзацына түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә: «яки муниципаль берәмлек халкын.»;

1.2. 5.7. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Гражданнарны сораштыру билгеләү турында карар җирлек Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең

рәсми сайты файдаланылырга мөмкин. Авыл җирлеге Советының гражданнарның сораштыру билгеләү турында норматив хокукый актында билгеләнә:

1) сораштыру үткәрү датасы һәм сроклары;

2) сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителгән (тәкъдим ителәчәк), сорауны (сорауларны) формалаштыру;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазе формасы;

5) сораштыруда катнашучы муниципаль берәмлек халкының минималь саны;

6)«Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru җирлекнең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/timershik адресы буенча һәм информацион стендларда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Тимершык авыл
җирлеге башлыгы                                        А.Х. Хаҗиев